СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

22.09.2025 № 1/8

На №__________ от_______________

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс игълан итү турында

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылуга бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясына, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы уставының 46 статьясына таянып, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәне 1 кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.
2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс игълан итәргә һәм аны әлеге карарның 1 пункты белән расланган Нигезләмә нигезендә уздырырга.
3. Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазифасын биләүгә дәгъва итүчеләрдән конкурска документларны 2025 елның «26сентябреннән 20255 елның «17» октябренә кадәр Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советы бинасында түбәндәге адрес буенча кабул итәргә: Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил пр., 46 йорт, 103 каб., Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазифасына кандидатураларны карау буенча конкурс комиссиясе 8

сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр, ял һәм бәйрәм көннәреннән тыш, көн саен эшли, тел. 8 (8552) 70-66-92.

4. Тукай муниципаль районы Советыннан конкурс комиссиясе әгъзаларын билгеләп, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазифасын биләүгә кандидатураларны карау өчен 6 кешедән торган конкурс комиссиясе составын 2 кушымта нигезендә расларга.

5. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе белән контракт формасын 3 кушымта нигезендә расларга.

6. Конкурс комиссиясенә 2025 елның «17» октябренә кадәр Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үткәрергә һәм конкурс нәтиҗәләрен һәм кандидатлар турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советына тапшырырга.

7. Әлеге карарны «Якты Юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Тукай муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

9. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Тукай муниципаль районы Башлыгы,
Совет Рәисе К.Р. Нәҗмиев